**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.11.2025 № 329

Аксубаево

Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 1 нче сыйныфларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү турында» 05.09.2025 ел, №239 карарына үзгәреш кертү хакында

Аксубай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 1 нче сыйныфларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү дәрәҗәсен саклап калу максатларында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 1 нче сыйныфларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү турында» 05.09.2025 ел, №239 карарына, 1 п. ны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә::

«1. Гомуми белем бирү оешмаларының 1 нче сыйныфларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләргә 2025 елның 1 сентябреннән дәрестән тыш эшчәнлеккә (ИЗО һәм музыка) чыгарылган 1 сәгатькә дәрес эшчәнлегенең 1 сәгатенә тиң күләмдә тарифлаштырырга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.С. Тимирясовка йөкләргә.

Җитәкче: С.Ю. Зайцев